## Сүз башы

Табышмак — халык иҗатының бик борынгы һәм үзенчәлекле жанрларының берсе. Исеменнән үк аңлашылганча, ул тыңлаучылар алдына нинди дә булса билгесез бер әйберне яки күренешне эзләп табу бурычын куя. Жанрның тагын *йомак* (яки *җомак*) дигән атамасы да бар. Монысы нәрсәнедер яшерү мәгънәсендә кулланылган *йому* фигыленнән ясалган. Элеккерәк заманнарда табышмак әйтешүне «Җомак әйтәм — җөмен тап» дигән сүзләр белән башлап җибәрү гадәте булган. «Җөмен тап» дигән сүз «җавабын тап» дигәнгә туры килә.

Төзелешләренә карап, табышмаклар берничә төргә бүленәләр. Аларның бер төре эзләп табылырга тиешле әйберне сурәтләп-тасвирлап бирә, сүзләр ярдәмендә аның рәсемен ясый. Шул рәсемдәге аерым билгеләр һәм сыйфатлар буенча без табышмакның җавабын эзләп табабыз. Мәсәлән: «Башы — тарак, койрыгы — урак». Башы һәм койрыгы булгач, димәк, сүз нинди дә булса хайван яки кош турында бара. Аның башы таракка, койрыгы уракка охшаган... Әлбәттә, күз алдыбызга әтәч килеп баса.

Инде «Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай» дигән табышмакны тикшереп карыйк. Иң элек беренче сыйфатка — билгесез әйбернең шар кебек йомры булуына игътибар итик. Андый әйберләр байтак: кабак, миләш, шалкан һ. б. Ләкин «кабак» дигән җавап табышмакта күрсәтелгән икенче сыйфатка ук туры килми. Чөнки аның эче кызыл түгел, ә сары. Миләш йомры да, кызыл да, әмма ул өченче сыйфатка җавап бирми. Безгә эче түгел, бәлки татлы әйбер кирәк. Шушы рәвешчә фикер йөртеп, дөрес җавапның «карбыз» икәнлегенә төшенү кыен түгел.

Табышмакларда әйберне тасвирлап күрсәтү өчен күп кенә сурәтләү чаралары файдаланыла. Алар арасында аеруча еш кулланылганы — *метафора.* Бу — грекча сүз, «күчерү» дигән мәгънәне белдерә. Метафора булып килгән сүзне һәрвакыт күчерелмә мәгънәдә аңларга кирәк. Әтәч

турында «койрыгы урак» дибез икән, бу кемдер аның койрыгын кисеп алган да шуның урынына урак бәйләп куйган дигән сүз түгел.

Инде сорау туа: сүзне болай күчерелмә мәгънәдә куллану, ягъни аннан метафора ясау өчен нинди шарт кирәк? Төп шарт — ике әйбер арасында охшашлык булырга тиеш. Әтәч койрыгы һәм урак, кикрик һәм тарак тышкы формалары белән бер-берләренә нык охшыйлар. «Ак сыер торып китәр, кара сыер ятып калыр» табышмагында төс охшашлыгы алынган: ак сыер — ак кар, кара сыер — кара җир. Йозак белән эт арасындагы охшашлык: алар икесе дә өй саклыйлар. Шуңа таянып, табышмак «эт» сүзен «йозак» дигән күчерелмә мәгънәдә куллана: «Кечкенә генә эт, өрми дә, җибәрми дә». (Йозак.)

Метафоралардан тыш, табышмакларда чагыштырулар да еш очрый. Алдарак тикшерелгән мисалда без карбызның формасы белән шарга, төсе белән канга, тәме белән балга чагыштырылуын күреп узган идек.

Кайчакта табышмакта эзләнелә торган әйбернең материалы, ягъни аның нәрсәдән ясалган булуы телгә алына. «Юкәгә утырдым, өрәңгегә карадым». Бу — каба. Аны юкә һәм өрәңге агачларыннан ясаганнар.

«Ары лап-лап, бире лап-лап, сөңге саплап, киез каплап» дигән табышмакны бик күпләр белә. Ул элекке заманда чабагач белән ашлык сугу процессын сурәтли. Картинаны күз алдына ачыграк китерү өчен, аваз ияртемнәре файдаланылган. Лап-лап — чабагач белән сукканда чыга торган аваз.

Алдарак әйткәнебезчә, хәзер карап узган мисалларның барысы да безнең күз алдына әйбернең сурәтен, рәсемен китереп бастыралар. Шуңа күрә мондый табышмакларны *сурәтле табышмаклар* дип атап булыр иде.

Болардан тыш, әле тагын *сорау-табышмаклар* һәм *арифметик табышмаклар* да була. Сорау-табышмакка дөрес җавап табу өчен анда куелган сорауның хәйләсен, четерекле ягын сизеп алырга кирәк. «Шалканны кайчан

чәчәләр?» дигән табышмакка, гадәттә, «яз көне», «көз көне», «җир кипкәч» кебек җаваплар бирәләр. Бервакыт хәтта «черки беткәч» дигән җавапны да ишетергә туры килде. Шулай итмәсәң, янәсе, аның яфракларын черки ашап бетерәчәк икән! Күбегезгә мәгълүм булганча, бу табышмакка дөрес җавап мондый: «Шалканны беркайчан да чәчмиләр, аның орлыгы гына чәчелә».

Димәк, биредә «шалкан» сүзе икенчел («орлык» дигән) мәгънәдә кулланыла. Ә менә табышмак әйтүче кеше үзенең соравында «шалкан»ның беренче, төп мәгънәсен күздә тоткан икән. Әгәр ул: «Шалканны чәчәләрме?» дип сораса, без әле аның тел төбенә җиңелрәк төшенер идек. Ләкин сорау «кайчан чәчәләр?» дип куела. Безнең бөтен игътибарыбыз шушы «кайчан»га юнәлә. Мондый сорау алмашлыклары җавап эзләүчене саташтыру, «эздән яздыру» өчен кертелә.

Сорау-табышмаклар кебек үк, арифметик табышмаклар да еш кына хәйләгә, алдауга корылган булалар. Мәсәлән, мондый табышмакны алыйк: «Бер ботакта 12 карга утыра иде. Аучы шуларның икесен мылтыктан атып төшерде. Ботакта ничә карга калды?» Әлбәттә, кайберләребез, озак уйлап тормыйча, «ун» дип җавап бирәчәк. Һәм бу, билгеле, дөрес түгел. Ботакта бер карга да калмый. Икесе җиргә егылып төшә, калганнары куркып очып китәләр. Мондый чакта коры арифметик гамәлләр белән мавыкмаска, ә табышмакның шартын күз алдына китереп, бераз зиһенне эшләтергә кирәк.

*Эпиграммалар, шарадалар* да табышмакларның бер төре итеп карала.

Шулай ук тагын *мәзәк-табышмаклар, хикәят-табышмаклар* һәм *әкият-табышмаклар* да бар. Борынгы патшалар, ыру башлыклары башка халыкларда да дини идарәне дә, хөкем эшләрен дә үз кулларында тотканнар. Татар табышмак-әкиятләрендә, төгәлрәге аларга нигезләнеп язылган хикәятләрдә («Мәликә китабы», «Шаһзадә Хәләф һәм Кытай патшасы кызы» һ. б.) патша

кияве булырга теләүчеләргә нигездә дини эчтәлекле табышмаклар, турыдан-туры Коръән аятьләре, хәдисләргә бәйле сораулар бирелә. Бу аңлашыла, чөнки әлеге әсәрләрнең тамырлары Ислам әдәбиятына барып тоташа. Ә мөселман дәүләтләренең хакимнәре, хәлифәләр шулай ук сәяси властьта да, рухи властьта да чикләнмәгән хокукларга ия булганнар.

Инде җиңелүчеләрнең җәзалануына килсәк, бу хакта фәнни әдәбиятта да кайбер мәгълүматлар очрый. Мәсәлән, гавай утрауларында яшәүче кабиләләр табышмак чишә алмаучыны утта яндырганнар. Һиндстанда исә мондый ярышларда җиңелгән кешеләрне суга батыру гадәте булган.

Табышмакны халык иҗатының бик борынгы жанры дигән идек. Аның килеп чыгуын фольклорчы галимнәр элекке замандагы *яшерен тел* күренеше белән бәйләп аңлаталар. Аң-белем дәрәҗәләре бик түбән булу сәбәпле, борынгы кешеләр табигать дөньясын җанлы итеп күз алдына китергәннәр. Аларның ышануынча, урман-кырларда, елга-күлләрдә ниндидер акыллы затлар яшәгән. Болар, янәсе, кешеләргә төрлечә зыян кылып торганнар. Менә шул «дошман көчләрне» алдау, өчен кешеләр «үзләре генә белә торган» *яшерен телдән* файдаланганнар. Борынгы аучы хайваннарны да кеше сөйләмен аңлый дип уйлаган. Шуңа күрә ауга чыгар алдыннан хайваннарны һәм коралларны үз исемнәре белән атау тыелган. Имештер, хайваннар ишетәләр дә, куркыныч килгәнне сизеп, качып китәләр икән. Ә инде аларны башка төрле *алмаш исемнәр* белән атасаң, мондый хәл булмый һәм ау уңышлы чыга икән. Мәсәлән, куянның «озын колак», «кыр тәкәсе», «чал тәкә», аюның «көрән», «бабай», еланның «майлы каеш», «җиз камчы» кебек алмаш исемнәре халык телендә бүгенгәчә сакланып калган. Еланның алмаш исемнәре икенче бер ышану белән дә бәйләнгән. Борынгы кешеләр үзләре өчен хәвефле, куркынычлы затларны сүз ярдәмендә юашландырып, буйсындырып була дип уйлаганнар. Әйтик, еланга

«камчы, камчы!» дип эндәшсәң, имеш, ул камчы кебек тыныч һәм хәрәкәтсез ятарга тиеш икән.

Яшерен тел һәм табышмак өчен уртак нәрсә шул: алар икесе дә әйберне үз исеме белән атамыйча, аны башка исем белән алмаштыралар. Кайчакта бу алмаш исемнәр аларның һәр икесе өчен дә бер үк булып чыга. Мисал өчен, куян турындагы «Чал тәкәдә мөгез юк», елан турындагы «Юл өстендә майлы каеш» дигән табышмакларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Борынгы заманнарда табышмак үзе дә, яшерен тел кебек үк, сихер-тылсым чарасы, табигатьтәге «ияләрне» буйсындыру, юашландыру чарасы булып хезмәт иткәндер дип уйлыйлар. Билгеле, ул бик борынгы табышмаклар бүгенге көндә дә әйтелеп йөрүче табышмаклардан нык кына аерылып торганнардыр. Кызганычка каршы, аларның үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланып калмаган.

Әлбәттә, яшерен тел белән табышмак арасында тигезлек билгесе куеп булмый. Яшерен тел фольклор жанры түгел, бәлки сөйләм, тел күренеше, читләтеп әйтү алымы гына. Ләкин барыбер табышмак яшерен телдән орлык алган, жанр булып формалашу процессында шул орлыкны үстергән һәм яңа сыйфатлар белән баеткан булырга охшый.

Хезмәт процессында кешенең серләренә торган саен тирәнрәк төшенүе, табигать көчләрен инде хыялда түгел, ә чын-чынлап буйсындырырга өйрәнүе нәтиҗәсендә, борынгы ышануларның җирлеге югала. Яшерен тел һәм аның белән бәйләнгән табышмакның баштагы тылсымчылык роле акрынлап юкка чыга. Табышмак сүз сәнгатенең үзенчәлекле бер төре буларак үсеп китә. Халык аңа күңел ачу, юаныч чарасы итеп карый башлый.

Табышмакларның күңел ачу чарасына әверелүе аларның күбрәк яшьләр һәм балалар арасында әйтелә башлавына китерә. Элекке татар авылларында табышмак әйтешү аулак өйләрнең «репертуарында» зур урын алып торган. Шул күңел ачу процессында кешеләр, табышмакка җавап